КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 9 апрель г.Казань № 219

Чирмешән муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Геология-разведка тикшеренү үзәге» АҖнең Чирмешән муниципаль районында урнашкан, шуның 1,6206 гектары - дәүләт милкендә, 1,3469 гектары С.В.Данчина милкендә булган 2,9675 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрдә күрсәтелгән чикләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:41:120403:328 | 0,3267 |
| 16:41:120403:329 | 1,2786 |
| 16:41:120403:330 | 0,01 |
| 16:41:120403:331 | 0,0036 |
| 16:41:120403:332 | 0,0017 |
| 16:41:120403:333 | 0,0019 |
| 16:41:120403:334 | 0,8087 |
| 16:41:120403:336 | 0,5327 |
| 16:41:120403:337 | 0,0036 |
| Барлыгы | 2,9675. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин